РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬКЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.58

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛКИ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422870, РТ Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,58

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay.ispolkom@tatar.ru сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Базарлы Матак авылы **КАРАР**

2019 нчы елның 11нче ноябре 389№

**“2020 елга “Әлки муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативларын раслау турында"**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 нчы елның 5 нче июлендәге 545 номерлы “Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыруны финанслау нормативларын исәпләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында" карарының 3 нче пункты нигезендә Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.2020 нче елга түбәндә бирелгәннәрне расларга:

2020 нче елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативлары;

Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында Нигезләмә.

2.”Әлки муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасы тәэмин итәргә:

гомуми белем бирү оешмаларын әлеге карарның 1 нче пунктында расланган балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативлары нигезендә финанслауны.

3. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми //htth:pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Йосыпов И.В.

Расланган
Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты Советы Карары
2019 нчы елның 11 нче ноябре 389 №

2020 нче елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделе исеме | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка,1 елга, сум | автотранспорт чарасының бер километр узуына ставка, сум |
| КАВЗ | 116398 | 37,42 |
| ПАЗ | 116656 | 37,35 |
| ГАЗ «Газель» | 110767 | 30,41 |
| УАЗ | 110314 | 29,04 |
| FIAT | 110057 | 27,47 |
| Peugeot Boxer | 110572 | 27,11 |
| Ford Transit | 110829 | 30,37 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 119128 | 35,31 |

Расланган
Татарстан Республикасы Әлки муниципаль
районы Башкарма комитеты Советы Карары
2019 нчы елның 11 нче ноябре 389 №

Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында Нигезләмә.

1.Гомуми нигезләмәләр

1.1.Әлеге Нигезләмә балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү механизмын билгели (алга таба - муниципаль хезмәт).

1.2.Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм автотранспорт чараларының факттагы йөгереше нигезендә исәпләнә.

1.3.Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары ел саен “Әлки муниципаль районы” муниципаль берәмлеге башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4.Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының факттагы йөгереше турындагы мәгълүмат автотранспорт чарасының расланган паспорты кысаларында эшләнгән автотранспорт чарасының факттагы йөгереше буларак Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча кабул ителә.

2.Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1.I муниципаль берәмлегенә муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m)$$ ,монда:

$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ - m модельле автотранспорт чараларының факттагы йөгереше;

$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру нормативының бер километрга ставкасы, сум;

$NF_{as\,m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда бер автотранспорт чарасына ташуны оештыру бәясе нормативының ставкасы, сум;

$M_m$ - m моделе автотранспорт чаралары саны, берәмлек;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделенең исеме;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус модельләре саны.